Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Красновидово авыл җирлеге Советы КАРАРЫ

2020 елның 30 октябре №13

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Красновидово авыл җирлегендә «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Красновидово авыл җирлегендә территориаль иҗтимагый үзидарәне оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибе турында» 2013 елның 19 декабрендәге 63 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Красновидово авыл җирлегендә территориаль иҗтимагый үзидарәне оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында » 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Красновидово авыл җирлеге Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Красновидово авыл җирлегендә территориаль иҗтимагый үзидарәне оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибе турында» 2013 елның 19 декабрендәге 63 номерлы Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Красновидово авыл җирлеге советы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Красновидово авыл җирлегендә территориаль иҗтимагый үзидарәне оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

13 статьяның 4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Территориаль иҗтимагый үзидарәне гамәлгә ашыручы гражданнар җыелышының, конференцияләренең аерым вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) территориаль иҗтимагый үзидарә органнары структурасын билгеләү;

2) Территориаль иҗтимагый үзидарә уставын кабул итү, аңа үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү;

3) территориаль иҗтимагый үзидарә органнарын сайлау;

4) территориаль иҗтимагый үзидарә эшчәнлегенең төп юнәлешләрен билгеләү;

5) территориаль иҗтимагый үзидарәнең керемнәре һәм чыгымнары сметасын һәм аның үтәлеше турындагы хисапны раслау;

6)территориаль иҗтимагый үзидарә органнары эшчәнлеге турындагы хисапларны карау һәм раслау.

7) инициативалы проектны тикшерү һәм аны хуплау мәсьәләсе буенча карар кабул итү.".

2. Әлеге карар 2021 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

3. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында игълан итәргә:

ТР, Кама Тамагы районы, Красновидово авылы, Совет ур., 4;

ТР, Кама Тамагы районы, Бортас авылы, Үзәк ур., 3;

ТР, Кама Тамагы районы, Антоновка авылы, Колхоз урамы, 9а,

шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга .

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Кама Тамагы муниципаль районының
Красновидово авыл җирлеге башлыгы,
Кама Тамагы муниципаль районының
Красновидово авыл җирлеге Советы рәисе И.В.Алешин